| СОВЕТ БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июнь 2019 ел. №112

**«Җир салымы турында»гы 14.11.2014 ел № 112 карарына (26.07.2018 ел №83 редакциясендә) үзгәреш кертү турында.**

РФ Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү турында " 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Борнак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Борнак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1."Җир салымы турында»гы 14.11.2014 ел, № 112 (26.07.2018 ел №83 редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 4 пунктның беренче абзацында «физик затлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 4 пунктның икенче абзацында «раслау» сүзен «салым ташламалары бирү турында гариза бирү һәм раслау» сүзтезмәсе белән,«гамәлгә ашырыла» сүзен " гамәлгә ашырылалар» сүзе белән алмаштырырга;

2. Әлеге карар «Хезмәт» район газетасында рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач һәм тиешле салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган рәвештә үз көченә керә.

Балтач муниципаль районы
Борнак авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Хәбибуллин